**Татарстан Республикасы**
**Азнакай муниципаль районы**
**Уразай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Уразай авылы № 95 "28" август 2023 ел

Татарстан Республикасы Азнакай мунициипаль районы Уразай авыл җирлеге Советыныц 2014елнын 27 нче февралендэге 63 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай мунициипаль районы Уразай авыл җирлегенең муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның муниципаль хезмәткәрләренең анда катнашу аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле беркетмә чараларына, эш сәфәрләренә һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә бүләк алу турында хәбәр итү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, аны сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаларны кертү тәртибе турында»гы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында
(15.02.2018 №86 карар редакциясендә)

«Аерым категория затларның вазыйфаи яисә хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу турында хәбәр итү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, аны сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаларны кертү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Президенты күрсәтмәсенә үзгәрешләр кертү хакында»гы күрсәтмәсе нигезендә

Уразай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Азнакай мунициипаль районы Уразай авыл җирлеге Советының 2014елнын 27 нче февралендэге 63 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның муниципаль хезмәткәрләренең анда катнашу аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле беркетмә чараларына, эш сәфәрләренә һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә бүләк алу турында хәбәр итү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, аны сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаларны кертү тәртибе турында»гы нигезләмәне (15.02.2018 №86 карар редакциясендә) түбәндәге эчтәлекле 13.1 пункт белән тулыландырырга:

«13.1. Әгәр кыйммәтле металллардан һәм (яисә) асылташлардан ясалган бүләккә карата мунициипаль вазыйфаларны биләүче затлардан, мунициипаль

хезмәткәрләрдән әлеге Нигезләмәнең 12 пунктында күрсәтелгән гариза килмәгән булса, яисә әлеге затлар мондый бүләкне сатып алудан баш тарткан очракта, кыйммәтле металллардан һәм (яисә) асылташлардан ясалган бүләк килмәгән булса, вәкаләтле структур бүлекчә (вәкаләтле орган яки оешма) тарафыннан "Россия Федерациясе кыйммәтле металлар һәм кыйммәтле ташлар дәүләт фондын формалаштыру, кыйммәтле металларны һәм кыйммәтле ташларны саклау, җибәрү һәм куллану буенча дәүләт учреждениесе" Федераль казна учреждениесенә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы каршындагы кыйммәтле металларны һәм кыйммәтле ташларны дәүләт фондына кертү өчен тапшырылырга тиеш.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: А.М.Шәрифуллина